**Каралды** **Килешенде** **Раслыйм**

**Методик берләшмә җитәкчесе**
**______ Рамазанова Р.Н.**
**Беркетмә № 1**
**25 нче август 2017 нче ел**

**Уку-укыту эшләре буенча**
**директор урынбасары**
**______ Г.Т.Исмагилова**
**28нче август 2017 нче ел**

**Мәктәп директоры**
**____ Г.Т.Сабирзянова**
**Приказ №71**
**28нче август 2017 нче ел**

# Татарстан Республикасы
# Сарман муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе
# “Сарман урта гомуми белем бирү мәктәбе” татар теле һәм әдәбияты укытучысы
# Рамазанова Раушания Наил кызының
# 9 нчы А сыйныфы өчен татар теленнән
# ***ЭШ ПРОГРАММАСЫ***

**Педсовет утырышында каралды**

**Беркетмә №1 28 нче август, 2017 нче ел**

**2017-2018 нче уку елы**

**Татар теленнән 9 нчы сыйныф эш программасына аннотация**

**Программаның исеме:**
9 нчы сыйныф өчен татар теленнән эш программасы.

**Программаны төзүче**: Хәмәтҗанова Фәнүзә Сәгыйь кызы.
"Татар теле" курсының эш программасы Федераль дәүләт белем бирү стандартларының таләпләренә туры китереп, ”Татар урта гомуми белем мәктәпләре өчен татар теленнән программа” 5-11 нче сыйныфлар. Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы, Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2010 ел, 9 нчы сыйныф өчен татар теле дәреслеге ( М.З. Зәкиев, С.М.Ибраһимов. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2015 ) укыту әсбабына нигезләнеп төзелде.

**Дәреслек:** Зәкиев М.З., Максимов Н.В. Татар теле: татар урта гомуми белем бирү мәктәпләренең 10-11 нче сыйныфлары өчен дәреслек. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2016.

**Программаны үтәү вакыты:** 2017 –2018 нче уку елы

**Сәгать саны**: Атнага 2 сәгать –барлыгы 68 сәгать

**Контроль төре:**
1.Өй эшләрен даими тикшереп бару
2.Укучыларның мөстәкыйль эшләүләрен булдыру һәм аны башкаруны контрольдә тоту.
3.Темалар буенча тест биремнәрен башкару
4. Чирек ахырында контроль эшләр телдән җавап, диктант,мөстәкыйль эш, тест, изложение, сочинение.

.
**Эш программасының структурасы:** титул бите,аңлатма язуы, Белем дәрәҗәсенә таләпләр,укытуның көтелгән нәтиҗәләре, метапредмет нәтиҗәләр, предмет нәтиҗәләр, тематик планлаштыру, укытуны матди- техник яктан һәм мәгълумати яктан тәэмин итү, әдәбият исемлеге, мәгълүмат чыганаклары, календарь-тематик план .

**Арадаш аттестация**: контроль тес т формасында үткәрелә.

**Аңлатма язуы**

Программа нигезенә Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыкларының мәктәпләрдә урта һәм тулы белем алу стандартлары алынды. Эш программасы түбәндәге документларны исәпкә алып төзелде:

1. 1. “Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында” Татарстан Республикасы Законы (2004 нче ел, 1 нче июль).
2. “2004-2013 нче елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт программасы” (2004 нче ел, 11 нче октябрь).
3. Россия Федерациясенең 309-ФЗ номерлы Законы (2007 нче ел, 1 нче декабрь).
4. Татар теленнән гомуми белем бирүнең дәүләт стандарты. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы. – Казан, 2008.
5. Татар телендә урта (тулы) гомуми белем мәктәпләре өчен татар теленнән программа. 1-11 нче класслар.Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2011.
6. Сарман урта гомуми белем бирү мәктәбе” муниципаль белем бирү бюджет учреждениесенең 2017-2018 нче уку елына укыту планы.

9 нчы сыйныф өчен программада татар теленә 68 сәгать каралган. Эш программасы да, мәктәпнең укыту планыннан чыгып, татар телендә урта (тулы) гомуми белем мәктәпләре өчен татар теленнән программага (1-11 нче класслар.Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2011) нигезләнеп, атнага 2 сәгатьтән 68 сәгатьлек итеп төзелде. Һәр тема программада каралган сәгать санынча өйрәнелә.

Үткәннәрне тирәнәйтеп кабатлауга 24 сәгать, стилистика һәм сөйләм культурасын өйрәнүгә 17 , ә тел турында мәгълүмат бирүгә 10 сәгать алынды. Программада бәйләнешле сөйләм үстерү дәресләренә 10 сәгать күрсәтелгән.. 9 нчы сыйныф укучылары татар теленнән дәүләт имтиханын иҗади биремле изложение формасында тапшыралар. Шуның өчен 10 сәгать бәйләнешле сөйләм үстерү дәресләреннән изложение язуга 6 сәгать ( 3 изложение 2 шәр сәгать исәбеннән) вакыт итеп алынды. Татар урта гомуми белем мәктәпләре өчен татар теленнән программада 9 нчы сыйныф укучыларына 4 диктант (шулардан 2се контроль) язу тәкъдим ителә. Программада күрсәтелгән 4 диктант эш планына кертелде, һәм алар өчен вакыт язма эш тикшерү максатында тоткан темалар исәбеннән алынды . “Конспект, тезис” 2 сәгатьлек теманың 1 сәгате кушма җөмлә эчендә тыныш билгеләре кую буенча күнегүләр эшләүгә алынды. Алдагы елларда имтиханнарны БРИ рәвешендә бирүне истә тотып, 2 дәрес тестлар эшләтүгә алынды. Кабатлауга, күнегүләр эшләтүгә 2 дәрес бирелде.

Программада “Морфология” темасына 2 сәгать каралган. Әлеге бүлек үз эченә 12 сүз төркемен, сүз төркемнәренең төрле грамматик формаларын кабатлауны ала. Укучыларның имтихан эшен язганда, сүз төркемнәрен, аларның төрле грамматик формаларын уңышлы куллану күнекмәләрен үстерү максатыннан, бу темага 1 сәгать бәйләнешле сөйләм үстерү өлешендә бирелгән язма эшләрне бергәләп тикшерүдән алынды.

Укучыларның гомуми грамоталылыгын тикшерү һәм үстерү өчен төрле характердагы диктантлар, шулай ук сүзлек байлыгын арттыру, бәйләнешле сөйләм үстерү, логик фикерләү дәрәҗәсен камилләштерү максатыннан сочинение һәм изложениеләр яздырыла.

Эш программасы тел белеме тармаклары арасында системалылык һәм эзлеклелек, фәннилек, аңлаешлылык принципларын истә тотып төзелде.

## Татар телен укытуның максатлары

- Укучыларда туган телгә хөрмәт тәрбияләү, аның иң зур рухи кыймммәт булуын аңлату.
- Укучыларның сөйләү һәм фикерләү сәләтен үстерү, татар телен тормышның төрле өлкәләрендә иркен куллана алырлык шәхесләр итеп тәрбияләү.
- Татар теле, аның төзелеше, кулланылышы турында мәгълүмат бирү; сүз байлыгын арттыру; әдәби телнең төп нормаларын һәм стилистик мөмкинлекләрен ачык аңлату, тиешенчә куллана белү күнекмәләре фомалаштыру.
- Сөйләм культурасын тәрбияләү.

## Татар мәктәпләрендә татар теле укытуның төп бурычлары

1. Татар теленең барлык тармаклары буенча эзлекле рәвештә фәнни белем бирү.
2. Сөйләм эшчәнлеге  төрләре буенча ныклы күнекмәләр булдыру. Туган телдә матур һәм дөрес аралашырга өйрәтү.
3. Телдән һәм язма сөйләм осталыгы һәм күнекмәләрен камилләштерү, татар теле мөмкинлекләреннән тулысынча файдалана белергә өйрәтү.
4. Татар телен башка фәннәр буенча белем алу чарасы буларак кулланырга өйрәтү күнекмәләре булдыру.
5. Укучыларның логик фикеләү сәләтләрен үстерү.
6. Дәреслек, өстәмә һәм белешмә әдәбият белән эш итү, уку, язу күнекмәләрен камилләштерү.

## 9 нчы сыйныф укучыларының әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр

- Тел буенча мәктәп программасында үтелгән күренешләрне билгели, анализлый, аңлатма бирә алу. Аларны сөйләмдә куллану, тыныш билгеләрен дөрес куя алу.
- Сөйләм төрләрен (сочинение-сыйфатлама, сочинение-хикәяләү; сочинение-хөкем йөртү) жанр формаларын саклаган хәлдә,  сөйләм культурасына куелган таләпләргә туры китереп,  сөйләмә һәм язма формада  эшли белү.
- Эш кәгазьләреннән хат, белешмә, мәкалә, расписка, акт, гариза һәм беркетмәләрне мөстәкыйль рәвештә яза алу.
- Сөйләмә Һәм язма формаларда сочинениеләрне, сөйләмнең төрле төрләренә туры китереп, төрле жанрда язу. Аларны тулыландыру һәм стилистик яктан шомарту.

**9 сыйныфта татар теленнән үзләштерелергә һәм камилләштерелергә тиешле гомумкүнекмәләр**

| Уку эшчәнлеген оештыра белү юнәлеше | Китап, өстәмә чыганак белән эш итә белү | Фикерләү белән бәйле күнекмәләр | Телдән һәм язма сөйләм үстерү һәм аралаша белү юнәлеше |
|---|---|---|---|
| 1. Укытучы тәкъдимнәре нигезендә өстәмә уку һәм үзлегеңнән белем алу эшчәнлеген планлаштыра алу.<br>2. Аларны башкару чараларын билгеләү һәм анализлау.<br>3. Эшчәнлеккә үзконтроль һәм үзбәя куя белү.<br>4. Предмет буенча оештырылган олимпиадаларда актив катнашу.<br>5. Тестлар эшли алу. | 1. 1. Дәреслек һәм төрле чыганаклар белән мөстәкыйль эш итә белү.<br>2. Төрле текстлардан төп фикерне аерып ала белү, текстның логик схемасын билгеләү, гади һәм катлаулы план белән эш итү. Тексттан мәгълүмат алу техникасын камилләштерү.<br>-Катлаулы булмаган темаларны мөстәкыйль өйрәнү. Эзләнү таләп итә торган мәсьәләләрне чишү юлларын үзләштерү. -Логик схемаларны, графикларны мөстәкыйль төзү. Эчтәлекне аңлап, тиешле тизлектә, уку елының беренче яртыеллыгында — 80-125 сүз; уку елының икенче яртыеллыгында — 85-130 сүз уку.<br>3. Тәнкыйтькә караган әдәбият белән эш итә белү. Сүзлекләр, белешмә әдәбият һәм иҗтимагый сәяси әдәбияттан файдалана белергә өйрәнү. | 1. Уку мәсьәләсен куя белү.<br><br>2. Танып-белү активлыгын үстерү.<br><br>3. Яңа теманы аңлауга мотив тудыру.<br><br>4. Төшенчә, атама (термин), кагыйдә, закончалыкларны аңлап кабул итү күнекмәсен камилләштерү.<br><br>5. Логик алымнардан чагыштыру, анализ, гомумиләштерү, нәтиҗә ясау күнекмәләрен камилләштерү.<br><br>6. Грамматик анализ төрләрен практик үзләштерү:<br><br>а) сүзтезмәләргә анализ ясау;<br><br>ә) җөмлә кисәк-ләренә анализ ясау;<br><br>б) гади һәм кушма җөмләгә синтаксик анализ ясау;<br><br>7. Тикшеренү ысуллары:<br><br>а) модельләштерү;<br><br>ә) охшатып эшләү. | 1 Телдән сөйләм:<br><br>• сорауны характерына һәм максатына карап җавап бирә белү. Мәгълүмат алу, системалаштыру максатында әңгәмә үткәрә белү;<br>• план, тезис, таблица, график тибында гомумиләштереп җыйнак җавап әзерли һәм җавап типларын аера, нигезле рәвештә сайлый белү.<br>2. Язма сөйләм:<br><br>• цитаталарны күчереп алу, тезис, конспект, бәяләмә, иптәшеңнең җавабына рецензия, язганда тиешле кыскартулардан файдалана белү;<br>• фикер йөртү элементлары кертеп, гади яки катлаулы план төзеп сочинение язуны камилләштерү;<br>• эш кәгазьләреннән хат, белешмә, мәкалә, расписка, акт, гариза һәм беркетмәләрне мөстәкыйль рәвештә яза алу. |

**Тематик планлаштыру**

1. Үткәннәрне тирәнәйтеп кабатлау – 24сәг.
2. Стилистика һәм сөйләм культурасы – 17 сәг.
3. Тел турында гомуми мәгълүмат – 9 сәг.
4. Бәйләнешле сөйләм үстерү – 10 сәг.
5. Кабатлау һәм имтиханнарга әзерлек – 4 сәг.
6. Диктант – 4 сәг.

**Программаның төп эчтәлеге**

| № | Төп темалар | Сәгать саны | Белем һәм күнекмәләр |
|---|---|---|---|
| 1. | **5-8 нче сыйныфларда үткәннәрне гомумиләштереп кабатлау**<br>Фонетика, орфоэпия һәм орфография. Аваз һәм фонема. Авазларның охшашлануы, чиратлашуы, йотылуы. Авазлар чиратлашуның мәгънә үзгәрешенә китерүе. Сузык һәм тартык авазларны дөрес итеп әйтү һәм язуда күрсәтү. | **4 сәгать** | Татар теленең орфоэпия кагыйдәләрен төгәл үзләштерү, аңа һәрчак игътибарлы булу. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | |
| 2. | Лексикология. Сүз, сүзлек составы. Сүзнең лексик һәм грамматик мәгънәләре. Синоним, омоним, антоним сүзләр. Фразеология. Профес-сионализм һәм диалектизмнар. Неологизм һәм архаизмнар. Алынмалар, аларның чыганаклары, үзләштерелеше. Лексик берәмлекләрне туплау, мәгънәләренә аңлатма бирү — лексикография. Сүзлекләрнең төрләре. | **5 сәгать** | Сүзлекләрнең төрләрен, төзелешен белеп, анардан иркен файдалана алу. Үзеңдә кульязма сүзлек булдыру, кирәкле сүзләрне сүзлеккә теркәп бару. |
| 3. | Сүз ясалышы. Тамыр сүз, ясалма сүз, парлы, тезмә һәм кыскартылма сүзләр | **3сәгать** | Сүзне мәгънәле кисәкләргә аеру һәм һәрберсенә аңлатма бирү, язуда шуларны шартлы билгеләр белән күрсәтү; ясалышы ягыннан сүз төрләренә аңлатма бирү, кушма сүзләрне дөрес язу. |
| 4. | Морфология. Сүз төркемнәре, аларның җөмлә төзүдәге әһәмияте. Кушымчалар, аларның җөмлә төзүдәге рольләре. Кушымчаларның язылышы, сүз ясалышы | **3сәгать** | сүз төркемнәрен һәм аларның үзенчәлекле грамматик билгелә-рен тану, мисалларны мор-фологик һәм өлешчә синтаксик яктан тик-шерү; |
| 5. | Синтаксик берәмлекләр.Гади җөмләдә тыныш билгеләре. Синтаксик берәмлекләр. Сүзләр арасында ияртүле һәм тезүле бәйләнеш. Бәйләүче чаралар, аларның төп үзенчәлекләре. | **5 сәгать** | Тексттан синтаксик берәмлекләрне бил-геләү, алар арасындагы бәйләнеш, бәйләүче чараларны анализлау |
| 6. | Кушма җөмләдә тыныш билгеләре | **4 сәгать** | Төрле калыптагы гади һәм кушма җөмләләр төзү, аларны сөйләмдә файдалану, дөрес интонация белән уку (әйтү), гади җөмлә синтаксисында өйрәнелгән тыныш билгеләрен дөрес куеп язу. |
| 7 | Стилистика һәм сөйләм культурасы.<br><br>Язма һәм сөйләмә стиль. Функциональ стильләр: матур әдәбият стиле һәм аның лексик, грамматик үзенчәлекләре; көндәлек матбугат стиле һәм аның үзенчәлекләре; фәнни стиль һәм аны үстерү өчен кирәкле шартлар; эш кәгазьләренә хас үзенчәлекләр; эпистоляр стиль һәм аның телебез тарихында тоткан урыны. | **6 сәгать**<br>+ | Төрле стильләрне аера, алардан файдалана белү. Эш кәгазьләреннән хат, белешмә, мәкалә, расписка, акт, гариза һәм җыелыш яки берәр утырыш беркетмәсен мөстәкыйль рәвештә яза алу |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Сөйләмдә синонимнарны куллану. Грамматик синонимнар һәм аларның төрләре: морфологик һәм синтаксик синонимнар. Морфологик синонимнарны сөйләмдә куллау үзенчәлекләре. Синтаксик синонимнарның үз эчендәге төрләре: сүзтезмәләрнең синонимлыгы, җөмлә кисәкләрен синонмик куллану, бер һәм ике составлы җөмләләрнең синонимлыгы, фигыль юнәлешләре белән бәйле синонимлык (актив һәм пассив төзелмәләр синонимлыгы), туры һәм кыек сөйләм синонимлыгы. Аналитик һәм синтетик иярчен җөмләләр синонимлыгы, иярчен кисәк һәм иярчен җөмлә синонимлыгы, тезмә кушма җөмләләрне синонимик куллану. Синтаксик калькалар һәм аларны сөйләмдә куллану. Сөйләмдә лексик чараларның( антонимнар, синонимнар, мәкаль, әйтемнәр, антоним, синоним) кулланылыш үзенчәлекләре. | 7 **сәгать** | Синонимнарның төрләрен аера белү. Текст эченннән табу һәм аларны үзгәртеп куллана белү. Синтаксик калькаларны сөйләмдә урынлы куллана белү |
| 8 | Сөйләм культурасы һәм аның нигезләре. Сөйләмгә куела торган таләпләр: 1) сөйләм төгәл булсын; 2) сөйләм. аңлаешлы булсын; 3) сөйләм саф булсын; 4) сөйләм җыйнак булсын; 5) сөйләм аһәңле булсын | **4 сәгать** | Язма һәм телдән сөйләм барышында сөйләм культурасына куелган таләпләрне саклау, редакцияли алу. |
| 9. | Телнең иҗтимагый әһәмияте. Тел үсеше турында гомуми мәгълүмат. Татар әдәби теле нормаларының борынгыдан ук үсеп килеше. Милли татар әдәби теле формалашу. Хәзерге татар әдәби теленең үсеш үзенчәлекләре. Ике теллелек. «Татарстан халыклары телләре турында» Татарстан Законы. Тел гыйлеменең әһәмияте һәм төп бүлекләре | **9 сәгать** | Татар әдәби теленең үсеш үзенчәлекләрен төгәл күз алдына китерү, тел үсеп торсын өчен, аның көндәлек кулланылышын тәэмин итү юлларын белү, димәк, «Тел Законыш тормышка ашыру юлларын үзләштерү. Тел гыйлеменең башка фәннәр белән бәйләнешен аңлата белү. |
| 10. | Диктант<br>**Бәйләнешле сөйләм үстерү.**<br>Изложение<br>Сочинение<br>Эш кәгазе | 4 сәг.<br><br>6 сәг.<br>1 сәг. | Бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен камилләштерү. Грамоталылыкны арттыру. Эш кәгазе үрнәкләре белән танышу, практикада куллана белү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Конспект, тезис<br><br>Изложениене бергәләп анализлау | 1 сәг.<br><br>1 сәг..<br><br>1 сәг. | |
| 11. | Үткәннәрне кабатлау.Күнегүләр эшләү.Имтиханга әзерлек.Тест. | 4 сәг. | |
| | Барлыгы | **68 сәгать** | |

**<u>Искәрмә.</u>** «Сарман урта гомумбелем бирү мәктәбе» муниципаль белем бирү бюджет учреждениесенең «Укыту предметы, курсы буенча эш программаларының төзелеше һәм тәртибе" турында» 29 нчы август, 2016 нчы елда педсоветта каралган(беркетмә № 1) һәм мәктәп директоры тарафыннан 2017 нче елның 29 нчы августында чыккан 109 нчы санлы приказы белән расланган нигезнамәсенең 5 пунктына таянып, дәресләр бәйрәм көннәренә һәм каникул көннәренә туры килү сәбәпле, 9 нчы сыйныфта программа сәгатьләрне берләштерү исәбенә үтәлә.

## Календарь - тематик план

| Т/с | Бүлекләр һәм темалар | Укучылар эшчәнлеге төрләре | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|
| | | | План | Факт |
| 1 | Фонетиканың өйрәнү объектлары һәм юнәлешләре | Аваз, фонема. Сузык һәм тартык авазларны дөрес итеп әйтү һәм язуда күрсәтү. Дөрес сөйләү һәм язу | 02.09Б<br>04.09В | |
| 2 | Сөйләмдә аваз үзгәрешләре. | Авазларның охшашлануы, чиратлашуы, йотылуы. Авазлар үзгәрү – чиратлашуның мәгънә үзгәрешенә китерүе | 07.09Б<br>06.09В | |
| 3 | Сөйләмдә аваз үзгәрешләре | Грамоталылык дәрәҗәсен билгеләү | 09.09Б<br>11.09В | |
| 4 | Административ контроль диктант «Якты күл».. | Авазларның охшашлануы, чиратлашуы, йотылуы. Авазлар үзгәрү – чиратлашуның мәгънә үзгәрешенә китерүе. | 14.09Б<br>13.09В | |
| 5 | Татар орфографиясенең төп принциплары | Татар телендә орфографиянең 5 принципка нигезләнүе | 16.09Б<br>18.09В | |
| 6 | Татар теленең сүзлек составы. | Телнең сүзлек составының лексика дип йөртелүе.Лексикология. Сүзнең лексик һәм граммматик мәгънәсе. Омоним, антоним, синоним сүзләр. Полисемия. | 21.09Б<br>22.09В | |
| 7 | Татар теленең сүзлек составы. | Фразеологизмнар.Профессионализм. Диалектизм.Неологизм.Алынма сүзләр. | 23.09Б<br>25.09В | |
| 8 | Лексик берәмлекләрне җыю һәм аларның мәгънәләренә аңлатма бирү. | Лексикография. Аңлатмалы, телара сүзлекләр. | 28.09Б<br>27.09В | |
| 9 | Лексик берәмлекләрне җыю һәм аларның мәгънәләренә аңлатма бирү. | Тексттан лексик берәмлекләрне билгеләү | 30.09Б<br>02.10В | |
| 10 | Сүз ясалышы юллары. | Сүзгә кушымчалар өстәү, сүзләрне кушу, сүзгә яңа мәгънә өстәү һ.б. | 05.10Б<br>06.10В | |
| 11 | Сүзләрнең ясалыш буенча төрләре. | Тамыр, ясалма, кушма, тезмә, кыскартылма, парлы сүзләр | 07.10б<br>09.10В | |
| 12 | Сочинение.” Сөйдергән дә- тел, биздергән дә - тел”. | | 12.10Б | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | 13.10В | |
| 13 | Сүз төркемнәре. Мөстәкыйль сүз төркемнәре. | Тел гыйлеменең аерым тармагы буларак морфологиянең сүз төркемнәрен, аларның грамматик билгеләрен һәм төрләнешен өйрәнүе. | 14.10Б<br>16.10В | |
| 14 | Сүз төркемнәре. Модаль, бәйләгеч төрләре. | Тел гыйлеменең аерым тармагы буларак морфологиянең сүз төркемнәрен, аларның грамматик билгеләрен һәм төрләнешен өйрәнүе. | 19.10Б<br>20.10В | |
| 15 | Әдәби әсәргә рецензия язу | | 21.10Б<br>23.10В | |
| 16 | Кушымчалар һәм аларның язылышы. | Ясагыч һәм төрләндергеч кушым-чалар; модальлекне белдерүче һәм бәйләгеч кушымчалар. Бифункциональ кушымчалар. | 26.10Б<br>27.10В | |
| 17 | Кушымчалар һәм аларның язылышы. | Кушымчаларның язылышы. | 28.10б<br>06.11В | |
| 18 | Синтаксик берәмлекләр. Гади җөмләдә тыныш билгеләре. | Тел гыйлеменең бер тармагы буларак, синтаксисның сөйләм төзелешен өйрәнүе. Тыныш билгеләре куюның нигезләре: тел төзелеше, мәгънәви нигез.Сүзләр арасында мәгънә мөнәсәбәтләре. | 09.11Б<br>10.11В | |
| 19 | Ия белән хәбәр арасына сызык кую очраклары. | Ия белән хәбәр арасына сызык куюның 6 очрагы. | 11.11Б<br>13.11В | |
| 20 | Аерымланган кисәкләр һәм аныклагыч янында ты-ныш билгеләре. | Ярым хәбәрлеккә ия булган хәл кисәкләр ияртүче сүздән ераклаштырылган булсалар, аларның өтер белән аерылулары. | 16.11Б<br>17.11В | |
| 21 | Изложение. | | 18.11Б<br>20.11В | |
| 22 | Өстәлмәләр, күзаллаулы баш килештәге сүзләр янында тыныш билгеләре | Өстәлмәләр.Күзаллаулы баш килештәге сүздән соң тыныш билгеләре. | 23.11Б<br>14.11В | |
| 23 | Эндәш сүзләр янында тыныш билгеләре. Тиңдәш кисәкләр, кереш сүзләр янында тыныш билгеләре. | Эндәш сүзләр янында өтер, өндәү билгесе куелу очраклары. Тиңдәш кисәкләр янында өтер, сызык, ике нокта куелу очраклары. | 25.11Б<br>27.11В | |
| 24 | Кушма җөмләдә тыныш | Кушма ж-дә тыныш билгеләре куелышының җөмләләрнең бәйләнеш | 30.11Б | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | билгеләре. Тезмә кушма җөмләдә тыныш билгеләре. | төренә һәм синтетик һәм аналитик төренә бәйлелеге. | 01.12В | |
| 25 | Синтетик иярченле кушма җөмләдә тыныш билгеләре. | Синтетик иярченле кушма җөмләдә өтер, сызык куелу очраклары. | 02.12Б<br>04.12В | |
| 26 | Аналитик иярченле кушма җөмләдә тыныш билгеләре. | Аналитик иярченле кушма җөмләдә тыныш билгеләре куюда бәй-ләүче чараларның нинди булуына, җөмлә төзелешенә таянып эш итү. | 07.12Б<br>08.12В | |
| 27 | Кушма җөмлә эчендә тыныш билгеләренә күнегүләр. | Кушма җөмлә эчендәге тыныш билгеләре куелуны кабатлау. | 09.12Б<br>11.12В | |
| 28 | Кушма җөмлә эчендә тыныш билгеләренә күнегүләр. | Кушма җөмлә эчендәге тыныш билгеләре куелуны кабатлау. | 14.12Б<br>15.12В | |
| 29 | “ Тыныш билгеләре” темасына диктант. | Укучыларның белемнәрен тикшерү. | 16.12Б<br>18.12В | |
| 30 | Әдәби сөйләм һәм аның стильләре. Стиль төшенчә-се.Әдәби, язма сөйләмгә хас төп билгеләр.Стилистика фәне. | Билгеле бер телдә сөйләшүче кешеләрнең фикерне аңлаешлы итеп һәм гасырлар буена урнашып килгән таләпләрне бозмыйча, тө-гәл итеп сөйләүләренә әдәби сөйләм дип әйтү. Стилистика. | 21.12Б<br>22.12В | |
| 31<br>32 | Сөйләм стиленең төрләре һәм үзенчәлекләре.Әдәби һәм публицистик стиль-ләр,аларның үзенчәлекләре. | Әдәби һәм публицистик стильләр.<br>Күчерелмә мәгънәлелеккә нигезләнгән тел-сурәтләү чаралары( метафора,эпитет, метонимия). | 23.12Б<br>08.01В<br>11.01Б<br>12.01В | |
| 33<br>34 | Фәнни, рәсми һәм сөйләмә стильләр.Төрле стиль һәм жанрга караган текст эшләү. | Фәнни стильдә гыйльми мәкалә, китаплар, белешмә, дәреслекләр, диссертацияләр язылуы. | 13.01Б<br>15.01В<br>18.01б<br>19.01В | |
| 35 | Хат язу. Эпистоляр стиль, аның телебез тарихында тоткан урыны. | Рәсми эш кәгазе буларак хат язу. | 20.01Б<br>22.01В | |
| 36 | Изложение. | | 25.01Б<br>26.01В | |
| 38 | Стилистиканың нигезе | Төп мәгънәләре охшаш булган сүзләр, фразеологик әйләнмәләр, сүз | 27.01Б | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 39 | буларак синонимия.<br>Сөйләмдә лексик чараларның кулланылыш мөмкинлекләре. | формалары, сүзтезмәләр, җөмләләрнең синоним дип аталуы. | 29.01В<br>01.02Б<br>02.02В | |
| 40-<br>41<br>42 | Синтаксик сино-нимнар.Синтетик һәм аналитик җөмләләр синонимлыгы. | Мәгънәләре һәм функцияләре белән бер-беренә якын, бәйләүче чаралар белән генә аерыла торган сүзтезмә һәм җөмләләрнең син-таксик синоним дип аталуы. | 03.02Б<br>05.02В<br>08.02Б<br>09.02В<br>10.02Б<br>12.02В | |
| 43<br>44 | Лексик һәм грамматик калькаларның татар сөйләмендә кулланы-лышы.Сөйләмдә лексик чараларның кулланылыш үзенчәлекләре. | Лексик һәм грамматик калькалар турында төшенчә бирү,аларның татар сөйләмендә кулланылышын күзәтү. Сөйләмдә лексик чараларның( антонимнар, синонимнар, мәкаль, әйтемнәр, антоним, синоним) кулланылыш үзенчәлекләре. | 15.02б<br>16.02В<br>17.02Б<br>19.02В | |
| 45 | Конспект, тезис. | Конспект, тезис турында башлан-гыч төшенчә бирү. | 22.02Б<br>23.02В | |
| 46 | Сөйләм культурасы һәм аның нигезләре.<br>Сөйләм төгәл булсын. | Сөйләм культурасының кешедә культураның бер билгесе булуы. | 24.02Б<br>26.02В | |
| 47 | Сөйләм аңлаешлы булсын.<br>Сөйләм җыйнак булсын. | Сөйләм аңлаешлы булсын өчен җөмләнең төзек булуы, кабатлауларның булмавы һ.б. | 01.03Б<br>02.03В | |
| 48 | Сөйләм саф булсын. | Сөйләм сафлыгына ирешү өчен туган телне аның байлыгын яхшы үзләштерү һәм шул байлыктан файдалана белү кирәк. | 03.03Б<br>05.03В | |
| 49 | Сөйләм аһәңле булсын. | Укучыны җәлеп итәр өчен сәйләмнең аһәңле, матур яңгырашлы булуы кирәклеге. | 08.03Б<br>09.03В | |
| 50 | “Сөйләм культурасы» темасына сочинение | | 10.03Б<br>12.03В | |
| 51 | Тел – иҗтимагый күренеш. Тел үсеше турында гомуми мәгълүмат.Башка телләр арсында тоткан урыны. | Иҗтимагый мөнәсәбәтләр, җәмгыять, телнең функциональ, структур үсеше. Татар теленең башка телләр арасында тоткан урыны. Телебездә халык мәдәнияте, тарихы чагылышы. | 15.03Б<br>16.03В | |
| 52<br>53 | Халык авыз иҗаты җәүһәрләре. Татар әдәби теленең үсеше. | Әдәби тел, борынгы төрки тел, иске төрки тел. | 17.03Б<br>19.03В<br>22.03Б<br>23.03В | |
| 54 | Татар милли әдәби теленең | Татар милли әдәби теленең хәзерге татар әдәби теле дип йөртелүе. | 24.03Б | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | формалашуы | | 06.04В | |
| 55 | Хәзерге татар әдәби теленең төп диалектлары, аларның язмы-шы. Төрле өлкәгә караган татар сөйләм этикеты нормалары. | Үзенчәлекле җирле сйләмнең диалект дип аталуы. Диалект төрләре.Төрле өлкәгә караган татар сөйләм этикеты нормалары, арала-шу культурасы үзенчәлекләре. | 05.04Б<br>09.04В | |
| 56 | Икетеллелек. | Икетеллелек, тулы һәм өлешчә ике теллелек.»Татарстан Республикасы халыклары телләре турында»ТР законы. | 07.04Б<br>13.04В | |
| 57 | Татар әдәби телен ассимиляцияләүгә рәсми чик кую. | Төрле өлкәгә караган этикет нормалары, халкыбызның аралашу культурасы үзенчәлекләре. | 12.04Б<br>16.04В | |
| 58 | Хәзерге татар әдәби теленең үсеш үзен-чәлекләре. | Хәзерге татар әдәби теленең үсеш үзенчәлеге. | 14.04Б<br>20.04В | |
| 59<br>60 | Тел гыйлеменең әһәмияте һәм төп бүлекләре. | Тел гыйлеме, лингвистика.татар тел гыйлеменең татарча укытыла торган башка фәннәр белән бәйләнешен аңлата белү. | 19.04Б<br>23.04В<br>21.04Б<br>27.04В | |
| 61<br>62 | Тестлар ярдәмендә татар теленнән белем сыйфатын тикшерү | Укучыларның белемнәрен тикшерү. | 26.04Б<br>30.04В<br>28.04Б<br>04.05В | |
| 63 | Сочинение язу | | 03.05Б<br>07.05В | |
| 64 | Әдәби әсәргә рецензия | Уку елы дәвамында үтелгәннәрне кабатлау. | 05.05Б<br>11.05В | |
| 65 | Ел буе үтелгәннәрне йомгаклауга контроль диктант. | Грамоталылык дәрәҗәсен тикшерү максатында. | 10.05Б<br>14.05В | |
| 66 | Диктантларга анализ. Тестлар эшләү. | Уку елын йомгаклау. | 12.05Б<br>18.05В | |
| 67<br>68 | Имти-<br>ханга әзерлек.Тезис язу | Укучыларның белемнәрен тикшерү. | 17.05Б<br>21.05В<br>19.05Б<br>25.05В | |

**Мәгълүмат һәм белем бирү чыганаклары**


1. Диктантлар җыентыгы (төрле авторлар).
2. Изложениеләр җыентыгы (төрле авторлар).
3. Вәлиева Ф.С., Саттаров Г.Ф. Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы, К..: Раннур нәшрияты, 2000.
4. Татар телендә тыныш билгеләре, Казан ,1985.- Ф.С.Сафиуллина, С.М.Ибраһимов, Э.Вафина.
5. Татар теленнән 222 тест/-Х.Сәлим.-Казан, “Яңалиф”, 2005.
6. Татар теленнән кагыйдәләр җыентыгы, Казан,2010.- Н.Гыймадиева, Р.Нуруллина.
7. Хәзерге татар әдәби теле/ Ф.С.Сафиуллина.- Казан :Мәгариф,2002.
8. Мәктәптә татар теле укыту. Гади җөмлә синтаксисы./ Н.В.Максимов,З.В.Шәйхразиева- Казан : Мәгариф, 2002.
9. Татар теле орфографиясенең кыен очраклары һәм укучыларның грамоталылыгын күтәрү юллары/Ә.Б.Шакирҗанова.-Казан: КДУ нәшрияты,2005
10. Татар теленнән бәйләнешле сөйләм үстерү дәресләре ( 8-11 сыйныфлар өчен) / Я.Х.Абдрәхимова.- Казан :Мәгариф,2005.
11. Татар теленнән мөстәкыйль эшләү өчен күнегүләр ( 8-9 сыйныфлар өчен) /Я.Х.Абдрәхимова.- Казан :Мәгариф,2005.


**Интернет ресурслар**: tugantelem.narod.ru, qushlawich.ru, gzalilova.narod.ru

**Диктант**

**Ялгыз йорт**

Әнә еракта Дим буена утырган ике мәчетле зур гына авыл. Якынрак барып карасаң , аның бер читендә урман шикелле куе бер бакчалык бар. Бакча бик күптән утыртылган булса кирәк: агачлар инде тәмам картайганнар. Бакчага карау белән , аңа инде күптәннән бирле адәм кулы орынмаганын белергә була. Аның койрыгы Дим буена барып терәлә. Икенче башындагы агачлар арасыннан аслы-өсле зур гына агач өйнең ташландык хәрабәсе күренә. Аның манзарасы гаять күңелсез: тәрәзәләр такта белән томаланган, түбәсендәге калайлар, буяулары күптән уңган, яңгырдан күгәреп, самовар моржасы төсле челтәр-челтәр булып беткәннәр.

Йөрүче булмаганга , ишегалдына ямь-яшел чирәм үскән. Төннәрен монда бигрәк тә тын була, тик ара-тирә мәче башлы ябалакның ачы тавыш белән кычкыргалаганы гына ишетелә.

Әбиләр кышкы озын төннәрдә , орчыкларын эрли-эрли, яннарына түгәрәкләнеп утырган балаларга ул хәрабә турында әллә нинди куркыныч әкиятләр сөйлиләр. Картлар исә , аның яныннан узганда , тирән уйга чумган бакчага бер карап алалар да мәгънәле генә итеп: „Бичара мирзаның балаларына бу нигездә рәхәт күрергә язмаган икән инде ...” – диләр. (152 сүз) С.Җәләлдән

**Изложение**

**Курорт – Казан**

Фәниярның дуслары аңа күптәннән курортка путевкаюллап йөриләр. Егетнең инде төшләренә диңгез , җимештән сыгылып төшкән агачлар керә. Аның беркайчан да көньякны күргәне юк. Җырларда җырланган кипарислар нинди була икән ? Ык буенда үскән талларга, зирекләргә охшаш микән ? Диңгезнең шаулавыниишетү күңелдә, бәлки, яңа хисләр уятыр. Яңа шигырьләр туар. Курортта дәвалану ягына килгәндә , Фәнияр зур файда өмет итми. Дүрт ел урын өстендә ятып , хәрәкәтләнергә тиешлеген оныткан әгъзаларны нинди дә кукертле су , кайнар ләмнәр генә дәвалый алмас. Хәзер калган сәламәтлекне югалтмаска һәм әз генә хәрәкәтләнә торган тәшне дә ныклап эшкә җигәргә кирәк. Ә иң мөһиме: уйланудан , эзләнүдән , язудан туктамаска. Тәнең өчен акылың хәрәкәт итсен ,аяклар урынына хыял йөрсен . Башка чара юк .

Көньякка китәргә өметләнеп ятса да , Фәниярга путевканы анда бирмәделәр. „ Ерак җиргә җибәрү куркыныч . Беренчедән , озаклап утырып тора алмыйсың , икенчедән , бик кызу вакыт , климат ярамас”, – диделәр. Көньяктагы кебек күкертле сулар белән дәвалый торган курорт Татарстанның үзендә дә бар икән . Фәниярны шунда җибәрделәр.

Бар яктан да татар авыллары белән чолганып алынган „Күкертле күл” курортын Фәничр бик ошатты. Табигать,
саф һава, яшел чирәм шундый сагындырган. Утырган коляскаңа өйләнеп тә карамыйча , яланаяк яшел чирәмнән йөгерәсе килә. Нишләптер, Фәниярда йөрү теләге табигатьбелән икәүдән-икәү калган чакта көчәя ... Сабый чакта синең бөтен тормышың алда була. Шуңа күрә һәрбер теләгеңнең тормышка ашачагына ышанасың. Ә хәзер ул ак каеннар тезелеп утырган аллеялар буйлап йөри дә, елга дулкыннарын кыйный-кыйный йөзә дә алмаячагын белә. Шул нәрсә аның бәгырен үтмәс пычак белән туктаусыз кискәләп тора.

Шулай да Фәниярга монда больницадагыдан күңеллерәк иде. Килгәненең икенче көнендә үк анализлар алдылар һәм егетне яңача дәвалый башладылар. Бер көнне күкертле ваннага чумдырдылар, икенче көнне ләмгә күмделәр. Әзрәк хәл алып өлгерүгә, массажы, физкультурасы көтеп тора. Дәвалау физкультурасы белән шөгыльләнүче кыз Асия Фәниярга ныклап тотынды. Физкультура кабинетына күтәреп кертеп сала да:

- Әйдә шуыш, үрмәлә. Җиде кат тирең чыксын. Бүтәнгә файдасы тимәсә, ашау үтәргә өйбәтрәк булыр, юкса ашавыңның рәте-чираты юк. Чыпчык хәтле генә дә ашамыйсың, - ди.
- Ә беләсезме? – ди Фәнияр. – Чыпчыклар көненә үз авырлыкларыннан күбрәк азык ашыйлар икән.

Физкабинетның идәненә калын матрас җәелгән. Бер башында үлчәү тора. Фәнияр шул үлчәүне немец танкысы итеп күз алдына китерә, үзенчә шуны „шартлатырга”тырыша. Ләкин дүрт-биш адым озынлыгындагы идәннең бер башыннан икенче башына шуышыр өчен, көне буе таш

кискән кадәр көч сарыф итә. Алай да үлчәргә барып җитә алмый. Аякларыннан кемдер тарта диярсең, шулкадәр авыр. Асия ял бирергә уйламый да. Идәнгә бер кап шырпы таратып ташлый да шуларны берәмләп җыярга куша. Һәр көн шулай дәвам итә

Фәниярның шигырьләр язуын, курортка дәваланып ятуын каян ишеткәннәрдер, беркөнне аның янына укучылар килде.

- Фәнят энем, - диде укытучылары, - без сезнең хәлегезне белергә, яраса, әзрәк концерт күрсәтергә килдек. Ләкин без бик күп, бүлмәгезгә генә сыймабыз.

Балалар Фәниярның газета-журналларда басылган шигырьләрен ятлап килгщнннщр ...

- Фщнияр абый, безгә яңа шигырьләрегезне укыгыз әле,- диделәр балалар.

Фәнияр ялындырып тормады. Тамагы карлыкканчы шигырь укыды, ә алар сорау арты сорау яудырдылар.

Фәниярның куторттан китәр көннәре дә якынлашты. (484 сүз) Ф. Яруллиннан

## Контроль диктант
## Әллүки

Ул кичне фронттан аеруча күңелсез хәбәр килде.

Күземә йокы кермәде. Нindiдер ташландык сарайда бөркүдән һәм авыр уйлардан йоклый алмый газапланып ятканнан соң, урамга чыктым. Урам буш һәм тын иде. Үз-үземне кая куярга белмичә, ачынып, тротуар буйлап киттем. Патрульләр, берничә мәртәбә туктатып, пропуск сорады.

Күпме йөргәнмен, хәтерләмим. Ничектер тар гына бер тыкрыкка барып чыктым. Шуида кинәт тынып калдым . Каяндыр, әкрен генә, зәгыйфь кенә булып, скрипка тавышы ишетелә иде. Башта мин колакларыма ышанмадым. Саташам дип торам. Безнең көй бит бу! Татар көе! „Әллүки”!

Мин аның зкпен генә, зәгыйфь кенә чыккан моңы агышына бирелеп, дөньядагы барлык нәрсәмне оныттым,берничә минут шулай басып тордым. Көй берничә тапкыр кабатланды. Ул һәр юлы, үзенең һәр авазы белән мине
биләгәннән- били барды. Мин, нindiдер эчке көчкә буйсынып, аны эзләп киттем. Ләкин ул анда, мин кергәч, кинәт югалды.

Яңадан урамга атылып чыктым. Инде ул урамда ишетелми иде. Югалды, дидем мин, өметсезләнеп, югалды . Юк, югалмаган икән, ул яңадан яңгырый башлады. (А.Шамовтан) (154 сүз)

## Якты күл

Билал берүзе урман сукмагыннан бара. Олы юлны калдырып, юри тар сукмактан кереп китте. Адашмас, югалмас әле, урман адаштырмый ул, йөри белсәң. Киресенчә, авыл малайлары — табигатьтә үскән егетләр шәһәрнең төз-төз урамнарында адашалар күп вакытта. Ә урман юллары адаштырмый аларны, чөнки табигатьтә, урманда алдау, хәйлә дигән яман нәрсә юк; анда барысы да ачык, күңелгә якын. Бөек табигыйлек монда.

Сукмак борылып-борылып барды да зур булмаган бер ачыклыкка килеп чыкты. Ә ул ачыклык күлгә килеп ялгана икән. Менә нинди икән ул Якты күл! Исеме җисеменә бик тә туры килә шул. Шушы ямьле урман уртасындагы сихри зәңгәр күз шикелле икән ул. Эчкерсез күңелләрнең яктылыгы шикелле икән ул! Мөлдерәмә тулы икән. Ап-ак каенлы ярлары, бу кадерле байлыкны ничек сакларга дигәндәй, тыныч кына уйга талган.
Билал, күл буена чыккач, башта бөтенләй туктап калды. Ул шушы гүзәллекне озаклап күзәтте. Күл өстенең ышанып булмастай зәңгәр тигезлеге вакыты-вакыты белән хәтта аны үзенә тарткан төсле иде. (150 сүз)

## Изложение
## Ана.

Автобус нигәдер озак килми торды. Көне буе җыелышып утырып талчыккан делегатларның түземлеге бетә башлады. Озакламый, төнгә ун тула бит.

Ниһаять, күзләрне яктыртып, автобус килеп туктады. Шофер:
-Делегатлармы? Рәхим итегез! — дип, салондагы утны яндырды.

Утыру озакка бармады. Кузгалыр алдыннан шофер, гафу үтенгән тавыш белән, безгә мөрәҗәгать итте:

-Иптәшләр, вокзалда безнең якка кайтучы бер егет бар, кереп алсак, ни диярсез?

Шофер автобусын вокзалның ишек төбенә үк китереп туктатты да кереп китте һәм озак та тормый бер кулына таяк, икенчесенә кечкенә чемодан тоткан егетне култыклап алып, чыкты.
Егетне күргәч, арткы рәтләрнең берсендә утырган апа урыныннан торды, без ни дә булса уйларга өлгергәнче, сүзсез генә барып, сукырны җитәкләде һәм үзенең янәшәсенә алып килеп утыртты.
Шунда кинәт, барыбызны да аптыраштa калдырып:
-Әнием, исәнме, әнием! дип, егет бу ананы кочагына кысты.
Улым, исәнме, бәгырькәем! Нишләп кайтасы иттең? Кыерсыттылармы әллә? Калтыранган тавыш белән сөйләнә-сөйләнә ана егеткә текәлде.
Сукыр егетнең «күрәсем килде» дигән сүзе безне сискәндереп җибәрде. Йөрәкләр өзелеп төштемени!
Әлеге ана безгә аңлатма бирүне кирәк тапты:
-Бер атна элек кенә үзен, авылдан машина алып, Әлмәткә сукырлар җәмгыятенә илтеп куйган идем. Әйбәт кенә эшләп калган идең бит, балам-бәгырем, ник кайтасы иттең? Кем белән кайттың?
Егет, сабый бала кебек, хатынга сыена төште:
-Ялгызым, әнием. Беләсем килде: үзем генә йөри аламмы икән? Яңадан мине илтеп йөрмәссең, әнием, үзем генә барырмын. Атна саен кайтып, сине күреп торырмын. И-и әни, кешеләр барысы да шундый яхшылар, безнең авылдагы кебекләр, ярдәм итәргә генә торалар.
Автобус эчендәге саран яктылыкта ана белән баланың күз яшьләрен һәм бәхетле йөзләрен күреп, без алар арасындагы якынлыкның никадәр югары, саф, тирән икәнлегенә ышандык.
Аларның авылы Бүләккә кайтып җиттек. Автобус туктаугa, ана белән бала төшен калдылар. Без аларның бер-берсенә сыена төшеп атлауларын озак карап тордык.
Шактый баргач, тынлыкны Сабирҗан абзый бозды:
-Ә бит ул аның баласы түгел...
-Чынлап әйтәсеңме?!
Үзебезнең авылга кайтып җиткәнче, шактый нәрсә белергә өлгердек.
Сөйгән егете белән туй ясарга җыенган Факиянең туе булмыйча кала. Күршеләре Мәрдан абзый белән Зәйнәп аиа, кечкенә малайлары Ришатны калдырып, бер-бер артлы үлепкитәләр. Факия малайны үзенә алып чыга, ул Факияне озакламый әни дип йөри башлый. Тик ул бала тумыштан сукыр була.
Факиянең сөйгән егете Сәйфи: «Бирнәгә сукыр бала алырга башыма тай типмәгән*.- дип, башкага өйләнә. Ләкин, гафу үтенеп, ничә мәртәбә Факия янына килә, тегесе сөйләшен тә тормый.
Башта ул Ришатны сукырлар мәктәбендә укыта. Илтеп куя, барып ала. Ялгызын бер дә юлга чыгармый. Шул бала бүген хәбәрсез-нисез кайтып төшсен инде. Күрәсең, сагынуына түзеп тора алмагандыр. Сагыну бит ул...
Шунда күз алдына тагын айлы сукмактан бер-берсен җитенләп атлаган ана белән бала килде. Башкалар ничектер, әмма мин, кайберәүләр үз балаларыннан да ваз кичеп, яңадан-яңа ятимнәр йортлары ачылган бу заманда Ришат хакына яшьлек мәхәббәтеннән баш тарткан Факияне, гомерем буена белгән кешем кебек, бик якын иттем. Ул миңа баласын коткару өчен дөрләп торган ут эченә ташланучы да, бозлы суга сикерүче дә, сабыйны ышыклап фашист пулясына каршы баскан батыр партизанка булып та күз алдыма килә иде. Кыз көенә картайган бу кеше Ана дигән бөек исемгә лаек түгелмени? Лаек, йөз тапкыр, мең тапкыр лаек. (480 сүз)

*Н. Әхмәдиевтән*

**Акъәби**

Акъәбинең соңгы еллардагы гомере балаларының кайтып китүләрен көтеп яшәү белән генә уза башлады. Дөрес, моннан ун ел элек, карты үлгәннән соң, балалары карчыкны калага тартып караганнар иде каравын, ләкин Акъәби гомер иткән нигезен ташлап китәргә теләмәде инде. Шушы Юлкотлыда туган ул, шушында гомер буе яшәгән, уллар-кызлар үстергән. Шушы Юлкотлы туфрагында аның атасы, анасы, күпме туганнары, яшьли үлгән сабыйлары, гомер иткән карты ята —я, ничек шуларның барысын да ташлап китәсең? Күп торасы да калмагандыр, ят җирнең туфрагына барып ятканчы, шушында үзенекеләр янында булыр дип уйлаган иде карчык ул чакта, һәм, һичнигә карамастан, хәзергә чаклы ул шушы нигезендә нык торды. Бигрәк тә оныкларын бик сагына карчык. Шулар кайтса инде, куанычы эченә сыймый, бөтен дөньясын оныта.  Тик бу бәләкәчләрнең әти-әниләре карчык янына гадәттә бик кыска вакытка гына кайталар.

Нишлисең, заманасы шулай туры килде инде. Акъәбинең сабый чактан исән калган балалары үсә тордылар, күрше авылның урта мәктәбен бетерә тордылар, һәркайсы, канат чыгарып, кош кебек, Юлкотлыдан еракка оча тордылар. Хәзерге вакытта бер улы белән бер кызы Өфедә яшиләр. Тагын бер кызы, врач булып чыкканы, Пермь өлкәсендә тора, ә иң кече малае, институтны бетергәч, Казакъстанга җибәрелгән иде, шунда — исеме дә билгесез бер шәһәрдә — кемдер булып эшли.

Өфедәге иң зур улы Суфиян, кызы Гөлбикә фәнни институтларның берсендә гыйльми эштә, кияве исә зур, җаваплы урында утыра. Кыскасы, барысы да зур кешеләр булып беттеләр. Кайсы галим, кайсы инженер, кайсы врач...

Тик менә бик бәхетле булып киткән балалары аңардан, ничектер, ераклаштылар шикелле... Менә зур улы Суфиян. Беркайда да эшләми, зур пенсия ала, машинасы бар, аңа бит Юлкотлыга ешрак кайтса да була хәзер... Ләкин, нишләтәсең аны, һаман вакытым юк дип зарлана, нindидер комиссияләрдә эшләп йөри, кышын бер-ике айга курортка китә, я булмаса үзе кебек погоннарын салган полковниклар белән төннәр буе карта сугып утыра, ә җәйгә чыккач, машинасына хатынын, бала- чагаларын утырта да я Кырымга, я хатынының урыс туганнарына — Саратовка китеп бара. Ә каладан йөз егерме чакрымда гына торган Юлкотлы читтә кала, әнисе-карчыкның алар өчен генә дип саклаган казлары келәтендә шул килеш эленеп тора.

Шулай да былтыр җәй Суфиянның җиткән улы Геннадий үзләренең машинасында «бабушканы» күрергә дип кайткан. Өч көн торды, өч көн Акъәби бер кәлимә башкортча белмәгән онығы алдына барлык сыйларын куйды, сүзсез генә аңа моңсу һәм назлы итеп карап утырды.

Менә шулай Акъәби, ялгыз башы улларын, кызларын көтеп, оныкларын сагынып, исән-имин генә яшәп килде. Әмма быел урынга ук ятарга мәҗбүр булды. (380 сүз)

Ә.Еникидән

**Гомумбелем күнекмәләрен бәяләүнең критерийлары һәм нормалары**

**<u>Язма эшләрнең күләме һәм аларны бәяләү:</u>**

Сүзлек диктанты –35-40 сүз

**Сүзлек диктантын бәяләү**

1. Пөхтә язылган, хатасы булмаган эшкә “5” ле куела.
2. Бер орфографик хаталы эшкә “4” ле куела.
3. Өч орфографик хаталы эшкә “3” ле куела.
4. Биш орфографик хаталы эшкә “2” ле куела.

Контроль диктант- ел башында 140 сүз,  ел ахырында 150 сүз

**Контроль диктантны бәяләү:**
1. Эш пөхтә башкарылса, хатасы булмаган эшкә “5” ле куела. (Бер – орфографик, ике пунктуацион хата булырга мөмкин.)
2. Ике орфографик, ике пунктуацион яки бер орфографик, дүрт пунктуацион хаталы эшкә “4” куела.
3. Дүрт орфографик, дүрт пунктуацион яки өч орфографик, алты пунктуацион хаталы эшкә “3” куела.
4. Алты орфографик, биш пунктуацион яки биш орфографик, сигез пунктуацион хаталы эшкә “2” куела.

**Изложение текстының күләме**
ел башында 450-475 сүз (220-240 –язма күләме)
ел ахырында 475-500 сүз (240-250- язма күләме)

**Изложениене бәяләү**
1. Тема тулысынча ачылган, фактик һәм техник хаталары булмаган, стиль бердәмлеге сакланган эшкә «5» ле куела. (Бер орфографик, ике пунктуацион яки ике грамматик хатасы булырга мөмкин.)
2. Текстның эчтәлеге темага нигездә туры килсә, фикерне белдерүдә зур булмаган ялгышлыклар җибәрелсә, бер-ике фактик, бер-ике техник хатасы булса, ике орфографик, ике-өч пунктуацион, бер грамматик хатасы булган эшкә «4» ле куела.
3. Язмада эчтәлек эзлекле бирелмәсә, стиль бердәмлеге сакланмаса, өч фактик, ике-өч техник хатасы булса, өч орфографик, дүрт пунктуацион, ике грамматик хатасы булган эшкә «3» ле куела.
4. Эзлеклелек, стиль бердәмлеге сакланмаса, язма эш планга туры килмәсә, фактик һәм техник хаталары күп булса, орфографик хаталарның саны дүрттән, пунктуацион хаталарның саны биштән, грамматик хаталар саны өчтән артса, «2» ле куела.

Сочинениенең күләме һәм аны бәяләү

Иҗади эшнең бер төре буларак, сочинение — укучының язма рәвештә үти торган эше. Ул бәйләнешле сөйләм үстерү күнекмәләре булдыруда зур әһәмияткә ия. Әдәби (хикәяләү, очерк, истәлек, хат, рецензия һ. б.), әдәби-иҗади, өйрәтү характерындагы, ирекле, рәсемнәр нигезендә үткәрелә торган һәм контроль сочинениеләр була.

**Сочинениене бәяләү**
1. Язманың эчтәлеге темага тулысынча туры килсә, фактик ялгышлары булмаса, бай телдә, образлы итеп язылса, стиль бердәмлеге сакланса, «5» ле куела. (Бер орфографик яисә ике пунктуацион (грамматик) хата булырга мөмкин.
2. Язманың эчтәлеге нигездә темага туры килсә, хикәяләүдә зур булмаган ялгышлыклар күзәтелсә, бер-ике фактик хата җибәрелсә, теле бай, стиль ягы камил булып, ике орфографик, өч пунктуацион (грамматик) яисә бер-ике сөйләм ялгышы булса, «4» ле куела.
3. Эчтәлекне бирүдә җитди ялгышлар, аерым фактик төгәлсезлекләр булса, хикәяләүдә эзлеклелек югалса, сүзлек байлыгы ярлы булса, стиль бердәмлеге дөрес сакланмаган җөмләләр очраса, өч орфографик, дүрт пунктуацион (грамматик) яисә өч-дүрт сөйләм хатасы булса, «3» ле куела.
4. Язма темага туры килмичә, фактик төгәлсезлекләр күп булып, план нигезендә язылмаса, сүзлек байлыгы бик ярлы булса, текст кыска һәм бер типтагы җөмләләрдән торып, сүзләр дөрес кулланылмаса, стиль бердәмлеге сакланмаса, биш орфографик, сигез пунктуацион (грамматик) яисә дүрт—алты сөйләм хатасы булса, «2» ле куела.

**Тестны бәяләү**

1.Тестның 90-100% дөрес башкарылган эшкә “5”ле куела.

2. Тестның 80-89% дөрес башкарылган эшкә “4”ле куела.

3.Тестның 65-79% дөрес башкарылган эшкә “3”ле куела.

4.Тестның 0-64% дөрес башкарылган эшкә “2”ле куела.

**Мөстәкыйль эшне бәяләү**

1. Мөстәкыйль эшнең 85-100% дөрес башкарылган эшкә “5”ле куела.
2. Мөстәкыйль эшнең 70-84% дөрес башкарылган эшкә “4”ле куела.
3  Мөстәкыйль эшнең. 50-69% дөрес башкарылган эшкә “3”ле куела.
4. Мөстәкыйль эшнең 0-50% дөрес башкарылган эшкә “2”ле куела.